ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 169-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, И.Г. Зәйниев, М.Х. Сәлахов, И.В. Терентьева тарафыннан кертелгән «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 169-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 15 апреле
№ 618-VII ДС

169-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
А.Р. Зарипов,
И.Г. Зәйниев,
М.Х. Сәлахов,
И.В. Терентьева
тарафыннан кертелә

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2025, № 29 (I өлеш), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 4 пунктындагы беренче абзацта «бер үк диндәге» сүзләрен төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Үзәкләштерелгән дини оешма башка үзәкләштерелгән дини оешма тарафыннан төзелергә мөмкин.»;

2) 12 статьяның 2 пунктында:
а) өченче абзацта «максатлары» сүзен «предметы, максатлары» сүзләренә алмаштырырга;
б) алтынчы абзацка «һәм алардан файдалану юнәлешләре» сүзләрен өстәргә;

3) 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«26 статья. **Дини оешмаларның керем китерә торган эшчәнлеге**

Дини оешмалар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә керем китерә торган эшчәнлекне башкарырга хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты 2026 елның 3 мартыннан үз көченә кергән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 20 февралендәге 30-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 30-ФЗ номерлы Федераль закон) туры китерү максатларында эшләнде.

30-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законга терминологияне Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезләмәләренә туры китерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелә.

Шулай итеп, аерым алганда, Граждан кодексында билгеләнгәнчә, гомуми кагыйдә буенча коммерциягә карамаган оешмаларның эшкуарлык эшчәнлеге белән түгел, ә керем китерә торган эшчәнлек башкарырга хокукын игтибарга алып, «эшкуарлык эшчәнлеге» термины «керем китерә торган эшчәнлек» термины белән алмамаштырыла. Шулай ук коммерциягә карамаган оешмаларның гамәлгә кую документлары турында нигезләмәләр төгәлләштерелә.

Шуңа бәйле рәвештә «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы законында «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закондагы кебек үк нигезләмәләр булганга республика Законына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Вөждан ирege турында һәм дини берләшмәләр турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы законы проектын
финанс-икътисадый нигезләү**

«Вөждан ирege турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.